ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.07.2022 г.Лениногорск №96

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 18 ноябрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен яңа редакциядә төзекләндерү кагыйдәләре турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә, прокуратураның 2022 елның 20 июнендәге 02-08-03 номерлы протестын карап, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 18 ноябрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

7 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«зур габаритлы калдыклар (ЗГК) - күләме аларны контейнерларга урнаштырырга мөмкинлек бирми торган каты коммуналь калдыклар (мебель, көнкүреш техникасы, торак биналарны агымдагы ремонтлаудан калган калдыклар һ. б.);»;

«үсемлек калдыклары - яшел утыртмаларны (ботаклар, яфраклар, агач калдыкларын) карап тоту процессында барлыкка килә торган калдыклар;»;

«каты коммуналь калдыклар (ККК) - физик затлар куллану процессында торак урыннарда барлыкка килә торган калдыклар, шулай ук шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында физик затлар тарафыннан торак урыннарда куллану процессында үзләренең куллану үзлекләрен югалткан товарлар. Каты коммуналь калдыкларга шулай ук юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган һәм физик затлар куллану процессында торак урыннарда барлыкка килә торган калдыклар составы буенча охшаш калдыклар да керә;»;

77 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Үсемлек калдыклары җайга салынмый торган бәя буенча тиешле рөхсәт документларына ия булган затлар (оешмалар) белән төзелгән килешү нигезендә чыгарылырга тиеш.»;

142 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«142. Умарталарны тоту урыннары (алга таба - умарталыклар) түбәндәге ераклыкларга урнаштырылырга тиеш:

торак пунктлардагы яисә гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару территорияләрендәге күрше җир кишәрлекләре чикләреннән (алга таба - бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре) кимендә 3 м, керү-чыгу юлларын әлеге участокларның чикләреннән капма-каршы якка юнәлдереп, яисә умарталарны күрше җир участокларыннан 2 метрдан да ким булмаган биеклектәге тоташ койма белән бүлеп алу шарты белән керү-чыгу юлларын ераклык һәм юнәлеш буенча чикләүләрсез;».

2. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә www.Leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры — Р.Г. Хөсәенов